**СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422735, Республика Татарстан, Высокогорский район, село.Ямашурма, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМЭ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ямаширмэ авылы, Совет урамы, 5

тел./факс 8(84365) 777-02, e-mail: Yamashl.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**04 июль 2023 ел** **№ 66**

## «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Ямаширмә авыл җирлеге Советының 30.04.2018 № 79 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Ямаширмә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы законнарга туры китерү максатыннан Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында " 30.04.2018 № 79 Ямаширмә авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының 02.10.2018 № 100, 14.12.2018 № 110, 30.09.2020 № 4, 20.10.2022 №52, 25.11.2022 № 56):

1 нче пунктта 15 нче абзацны алып ташларга;

- «дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләү өчен айлык процент өстәмәсе күләме һәм муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи хезмәт хакы күләме»12 нче кушымтаны чыгарырга;

- «Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә еллар буе хезмәт иткән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмә» 13 нче кушымта 12 нче кушымта дип саналырга тиеш.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында урнашкан, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Ямаширмә авылы, Совет урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarsta.ru Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматларының рәсми порталында һәм авыл җирлекләре бүлегендә http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Ямаширмә авыл җирлеге башлыгы Ф. К. Мөхтәров